■ Исламда балалар

# Ризаэтдин Фәхреддин нәсихәтләре

***Бисмилләһир-рахмәнир-рахим***

## АТА ВӘ АНА

Әй хөрмәтле балалар! Хезмәт күрсәткән кешеләр, яхшы күңелле кешеләр - һәрвакыт хөрмәттә булырлар вә якын күрелерләр, моны исә үзегез дә беләсездер. Хәлбуки, сезнең ата-аналарыгыз - сезгә иң авыр вә мәшәкатьле хезмәтләрен итteләр вә һаман да итәләр, һәрвакыт сезне кайгыртып, сезнең бәхетегез өчен тырышалар вә һәрвакыт сезнең өчен Аллаһы Тәгаләгә ялваралар вә дога кылалар. Моның өчен һәрникадәр аларның хезмәтләренә карышмавыгыз вә мәшәкатьләренең хакын үтәвегез мөмкин булмаса да - һаман аларга ихлас белән хезмәт итүче вә аларга хөрмәт күрсәтүче булыгыз!

Хосусан, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре, аларга гүзәл мөгамәлә күрсәтүне васыять иткән вә иң изге Рәсүл әфәндебез (салләл-лаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре: “Ата-аналарны риза итүче балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр”, - дигән мәгънәдә сүз сөйләгән.

Киләчәк көндә, хөрмәтле вә файдалы кешеләр булуыгызны ата вә анагыз һәрвакыт өмет итеп торалар вә Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән сорыйлар. Инде сез дә - мондый изгелекләргә каршы явызлык итүчеләрдән булмагыз! Һәм дә аларның нәсыйхәтләрен куркып вә өркеп түгел, бәлки мәхәббәт вә ихлас белән тотыгыз, чөнки алар бу дөнья хәлен озын тәҗрибәләре белән бик яхшы таныйлар вә сез белмәгән күп серләрне беләләр.

Кешенең буйсынучы булуы - күңеле яхшы булу билгеседер. Инде сезгә иң якын кешеләр дә, әлбәттә, ата вә аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта итагатьле булыгыз, гамәл вә сүздә аларга каршы килмәгез, бу сәбәптән аларның күңелләре дә рәхәтләнер, үз күңелләрегез дә вә дөньяда торуыгыз да гүзәл булыр.

Ата вә аналарыгыз хозурында бик әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз, ишарәләрен аңлагыз, алар белән артык кычкырыпмыйча, әдәпле итеп, ачык сөйләшегез. Алар аягүрә торганда, сез утырып тормагыз!..

Баһадирлык - адәм балаларында хөрмәтле бер сыйфаттыр. Олылар мәҗлесендә булып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү гакылны арттыра вә гыйлемлекне күбәйтәдер. Хәтта кечкенә балаларны, бөек адәмнәр мәртәбәсенә якын китерәдер. Шуның өчен, йөрәксез балалар кебек, аталарыгыз сөйләшеп утыруында катнашудан курыкмагыз вә белмәгән һәм аңламаган нәрсәләрегезне алардан сорагыз вә һәрнәрсәнең асылын белергә тырышыгыз!..

Урамда йөргән вакытларыгызда атагыз очраса, аңа һәм аның белән берлектә булганнарга сәлам биреп әмерләрен көтеп торыгыз! Әгәр дә утырып торган вакытыгызда килсә - ачык йөз белән аягүрә торыгыз!..

Атагыз һәрнәрсә бирер булса, үзенең мәрхәмәте белән бирер, шуның өчен, нәрсә булса да сораган вакытта, янында чит адәмнәр булмаган вакытта сорагыз, әгәр дә теләгән нәрсәләрегезне бирмәсәләр - күп борчымагыз, чөнки сезгә нәрсә кирәк вә нәрсә кирәк түгел икәнлеген вә сезгә нинди әйберләр яраклы булып, ниндиләре яраклы булмавын алар тагын бик яхшы беләләр.



Атагызның иң якын дусты булса да, атагыздан башка кешедән кирәк әйберегезне сорау гаеп эш вә гаилә хөрмәтен җибәрүдер. Шуның өчен барлык теләгән әйберләрегезне атагыздан сорагыз!

Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән кеше, олыгайгач та, акча тота белмәс, дөньяда гүзәл көн кичерә алмас. Бәлки бар байлыгын исраф итеп бәхетсез булып калыр. Шуның өчен атагыз тарафыннан бирелгән акчаларны тота белергә өйрәнегез. Сак булыгыз, “бу - аз гына” дия күрмәгез, чөнки бүген сезнең кирәкләрегез дә бирелгән акча кебек аздыр.

Кайбер балалар булыр ки: аталарының малларына ышанып, һичбер кәсеп вә эш юлына кермәсләр, бәлки ялкаулыкка гадәтләнерләр. Ахырда бер көн килер, акчалары да бетәр. Тереклек итәр өчен кулда һөнәр дә булмас. Шуның өчен ата малына ышанып тормыйча, бәлки никадәр бай баласы булсагыз да булыгыз, үзегезне кеше баласы санап, һөнәр өйрәнергә тырышыгыз!

Дөньяда торган вакытта, шатлыкларны сөйләр, кайгыларны чишеп әчне бушатыр өчен иң якын, иң ышанычлы бер кешегә мохтаҗ булынадыр. Ләкин бу эшләр тугрысында ата белән анадан артык һичкем булмас, чөнки болар баланың шатлыгы өчен хәтта үзеннән артык сөенәдер вә хәсрәтләре өчен кулдан килгән барлык чараларны күрүдә кимчелек итмәсләр. Шуның өчен серләрегезне боларга сөйләгез, серләрегезнең хәзинәләре һәрвакытта ата вә аналарыгызның күңелләрен булсын!

Күзгә күренгән һәрбер нәрсәгә кызыгучы булмагыз, аналарыгызның җыеп куйган нәрсәләре вә кунаклар өчен дип хәзерләнгән әйберләре янында йөрмәгез вә зарар итмәгез! Чөнки аналарыннан рөхсәтсез мондый эшләр эшләүче балалар моның кебек эшләргә гадәтләнерләр вә, көннән-көн арттырып, ахырында (Аллаһы Тәгалә сакласын!) угры булырлар.

Бәдәнегез үсеп көч кергәч тә, кулларыгыздан килгән эшләрдә ата вә аналарыгызга ярдәм итүче булыгыз, бәлки шәфкать вә хезмәтләрегезне тагын да арттырыгыз, алар исә сезнең яшь вакытларыгызда вә иң зәгыйфь булган көнегездә тәрбияләп сезне үстергәннәр. Бер көн җитәр, сез дә ата булырсыз, исәпләп карагыз, шул көндә балаларыгыз хөрмәтегезне санламасалар, риза була белерсезме? Иң изге Рәсүл (салләл-лаһу галәйһи вә сәлләм әфәндебез хәзрәтләре: “Аталарыгызга изгелек итегез, сезгә балаларыгыз изгелек итегез, сезгә бвалаларыгыз изгелек итәр”, - дигән мәгънәдә бер сүз сөйләгән.

Кайбер балалар булыр ки: аталарының тәрбияләрендә вә мәрхәмәтләре кулләгәсендә рәхәтләнеп үсәрләр дә, үскәннән соң аталарының фикерләренә каршы килерләр, сүзләрен ишетмәсләр, аларның гамәлләрен аз күреп көләрләр. Сез шулай инсафсыз булмагыз! Аталарыгыз исә сезнең тугрыда җаваплы булмый, бәлки алар турысында сез җаваплы булачаксыз. Замана көннән-көн алга барып вә гыйлемнәр артып торганлыктан бу көндәге бөек бер галимнең иртәге көндә бер шәкерт дәрәҗәсендә калачагы табигыйдер. Өч катлы бина салу тугрысында булган мактау өченче куатны бина кылучыларга булган кебек, нигезне салучылар да гаепләнергә тиеш түгелдер.

Тиешсез бер эшкә кушкан вакытларында, һич тыгызланмыйча вә күңелләрне җәрәхәтләндермичә, бәлки әдәп вә инсаф белән эшнең турысын белдерергә тырышыгыз!

## ТУГАННАР

Туганнарыгыз - ата вә аналарыгыз соңында иң якын кешеләрегездер. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле вә мәрхәмәтле булыгыз! Боларның олыларын ата вә ана урынында санап, итагатьле булыгыз вә сүзләрен тыңлап гамәл итегез! Кечеләренә шәфкатьле булып, аларны бер дә рәнҗетмәгез вә каты күңелле булмагыз. Оятсызлык вә тәрбиясезлектә күчергеч булып күренмәгез, аларны сүкмәгез, кулларында булган нәрсәләрне тартып алмагыз. Чөнки болай итү аларның каннары бозылуга вә ата-ананы ачуландыруга сәбәп булыр.

Туганнарыгызда ярамаган бер эш күренер булса, яхшы сүз белән: “Болай булмагыз, гаеп эш бит!” - дип тыегыз вә әлеге эшнең килешмәгәнен аңлатып күрсәтегез, гүзәл юлга күндерегез!

Туганнарыгыз өстеннән ата вә аналарыгызга сүз әйтмәгез, чөнки болай булган балалар, мондый эшләргә гадәтләнеп, олыгайгач та сүз йөртүче булырлар. Бәлки булса, гүзәл эшләрне сөйләгез!

Туганнарыгызның әйтүләрен көтеп тормыйча, һәр эшләрендә ярдәмче булыгыз, кулыгыздан килгән изгелекләрне бер дә алардан кызганмагыз!

Туганнарыгызның серләрен гүзәл саклагыз, аларга шатлыклы хәбәрләр сөйләп (әгәр дә аларга зарар китерәчәк булмаса), яманнарын сөйләмәгез! Сүз вә гамәлләрегез белән аларга ихласлы булыгыз, гаепләрен яшерегез, һәрвакытта ачык йөз вә киң күкрәк белән каршы алыгыз!

Кайбер балалар булыр ки: аталары вафат булгач, мал бүлү хакында туган вә кардәшләр белән бозылышырлар, бер-берсе хакында әдәпсез мөгамәләдә булырлар, кыйммәтле вакытларын вә газиз малларын әрәм итәрләр, үзләренең кан вә җан кардәшләрен рәнҗетеп, читләрнең корсакларын туйдырырлар, бу юлда үзләре дә бәхетсез булырлар, ата вә аналарының да исемнәрен хөрмәтсез итәрләр, гаилә вә кабиләләрне мәсхәрәктә калдырырлар. Сез үскәч, мондый балалар кебек булмагыз, гаеп эштер! Бәлки, туганнарыгыз белән һәрвакытта берлектә булыгыз! Нәҗесне (бозык холык вә ачу сәбәпләрен) һәрвакыт туфрак астына күмегез, болай булганда аз мал да күп күренер, кыска гомердә бәрәкәтле булыр.

## ЯКЫН КАРДӘШЛӘР

Ата-ана вә туганнарыгыздан соң сезгә якын кешеләр - үзегезнең кардәшләрегездер. Болар да сезнең сәгадәтегезне вә бәхетегезне теләрләр. Шуның өчен боларга да ата-ана вә туганнарга булган мөгамәлә кебек мөгамәләдә булыгыз. Шатлык вә кайгы вакытларны уртаклашыгыз, хаҗәтләрне гүзәл сурәттә үтәгез!

Ялкау вә бозык холыклы затларга изгелек итү - ялкаулыкларны арттырырга вә бозыклыкларны көчәйтергә сәбәп булганы өчен, якын кардәшләрегезгә изгелек иткән вакытыгызда, кәсеп сәбәпләреннән мәхрүм калганнарны вә саф күңелләрне аерым карагыз! Ягъни тиешле урыннарга сарыф итәргә тырышыгыз!

## КҮРШЕЛӘР

Кардәшләрдән соң иң якын кешеләр - күршеләрегездә. Шуның өчен күршеләр белән гүзәл мөгамәләдә булыгыз, алар белән дус торыгыз, шатлык вә хәсрәт вакытларында уртаклашып, хәстә вә чирле вакытларында хәлләрен сорагыз, хезмәтләре булса күрегез, алар өчен даими догачы булыгыз!

Күршеләрнең нәмәхрәм, ягъни ерак кардәш һәм бөтенләй кардәш булмаган кеше булганнарына күз салмагыз! Койма ярыкларыннан карамагыз! Һичбер эштә аларның хәтерләрен калдырмагыз! Хөрмәтле вә гыйффәтле, ягъни намуслы кешеләр шулай булырлар.

## ӨЙ ЭЧЕНДӘ

Өй эчендә булганнар белән гүзәл мөгамәләдә булу шәригать каршында иң сөекле эштер. Вә шуның өчен өй эчендә булганнар хакында әдәпле вә миһербанлы булыгыз. Өй эчендә булганнар рәхәт вә шат булсалар, сезгә дә рәхәтлек вә шатлык булыр.

Өй эчендә хезмәт итүчеләр булса, аларны хурламагыз, күңелләрен боектырмагыз, йомыш кушсагыз, “Шулай ит, болай ит!” димичә, бәлки “Шулай итә күрегез, мәрхәмәт итеп болай эшләгез лә! Шулай итсәгез - гүзәл булыр иде!” - дип әйтегез: хезмәтчеләр белән болай булу - күркәм холыклылыктыр. Тәрбияле адәмнәр гадәттә шулай булыр. Йомшак сүзле булу - адәм баласы өчен бөек бер байлыктыр.

Хезмәтчеләргә мәрхәмәтле булыгыз, алар каршында үз-үзегезне тота белегез. Хаталыклары булганда гафу итегез, алар белән уйнамагыз, көлке сөйләшмәгез, кирәк булмаганда, аларның сүзенә катышмагыз, чөнки бу нәрсәләр, беренчедән, тәрбиясезлек билгеседер вә, икенчедән, алардан яман сүз ишетергә вә холык бозылырга сәбәп булыр.

Хезмәтчеләр - өй эчендә булган серләрнең ачкычларыдыр, һәр күргәннәрен сөйләрләр вә ишеткәннәрен фаш итәрләр. Шуның өчен сак булыгыз: читләрдән яшереләчәк сүзләрне алар каршында сөйләмәгез, акча вә байлыгызны аларга белдермәгез, һәр эшләгәннәрен күзәтеп торыгыз, моның сәбәпле аларның мәкереннән имин булырсыз!

Өй эчендә булган серләрне чит кешеләргә сөйләмәгез!

Йокыдан иртә торыгыз вә торганнан соң, сәламәтлегегез өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итегез, соңыннан тәһарәтләнеп намаз укыгыз!